**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 октябрендәге 4544 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 19 августындагы 2050 номерлы «Казан шәһәренең ачык мәйданчыкларында урам музыкантлары, рәссамнары, артистлары эшчәнлеген координацияләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәренең ачык мәйданчыкларында урам чыгышларын үткәрүне тәртипкә салу максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 19 августындагы 2050 номерлы «Казан шәһәренең ачык мәйданчыкларында урам музыкантлары, рәссамнары, артистлары эшчәнлеген координацияләү тәртибен раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 11 маендагы 1357 номерлы, 2022 елның 8 августындагы 2611 номерлы һәм 2022 елның 20 октябрендәге 3569 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Казан шәһәре Башкарма комитетының мәдәният идарәсе (А.И.Абзалов) белән килештереп, артистларның чыгышлары өчен мәйданчыклар исемлеген формалаштыра торган вәкаләтле органнар итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләрен (А.И.Салихов, Р.Х.Шәмсетдинов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасын (А.Ш.Фәезов) билгеләргә»;

1.2. 1 номерлы кушымтаның 2.2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2.2. Урам чыгышлары өчен мәйданчыклар исемлеге мәгълүмат системасында урнаштырыла. Мәйданчыклар рөхсәт ителгән тавыш дәрәҗәсе, урам чыгышларында катнашучылар саны буенча бүленгән:

- музыкаль – тавыш дәрәҗәсе 90 децибелга кадәр булган чыгышлар өчен, тавыш көчәйтү җайланмасын куллану рөхсәт ителә;

- музыкаль-акустик – тавыш дәрәҗәсе 60 децибелга кадәр булган чыгышлар өчен, портатив колонкалар яки комбокөчәйткеч рәвешендә тавыш көчәйтү җайланмаларын куллану рөхсәт ителә. Бәрмә музыка уен коралларыннан (барабаннардан) торган акустик җайланмалар, шулай ук бердән артык санда бакыр тынлы музыка уен кораллары кулланылмый торган мәйданчык;

- акустик – тавыш көчәйтү җайланмаларын, бәрмә музыка уен коралларыннан (барабаннардан) торган җайланмаларны һәм аларның компонентларын (барабаннарны, тәлинкәләрне), шулай ук бакыр тынлы музыка уен коралларын кулланмыйча чыгышлар ясау өчен».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**